Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР

10 ноябрь 2025 ел

№ 2

Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Кече Аксубай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Бердәм гавами хакимияттә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Яңа Аксубай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә КАРАР бирәм::

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлегенең Кече Аксубай торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2025 елның 21 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Кече Аксубай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

1. **Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су чыгаруны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру:**
- су белән тәэмин итү системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм Кече Аксубай авылында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау. (тирәнлек насосын ремонтлау һәм алмаштыру, сүүткәргечне ремонтлау ( товар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)

**2. Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;**
- Кече Аксубай торак пункты территориясен төзекләндерү (Кече Аксубай торак пункты территориясендәге үсентеләрне чаптыру (ягулык-майлау материаллары, трактор чапкычына һәм бензотриммерларга запас частьләр, чыгым материаллары сатып алу).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыенын Татарстан Республикасы Аксубай районы Кече Аксубай авылы Лесная урамы, 21 нче йорт адресы буенча урнашкан йорт янында уздырырга.

4. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында http://aksubayevo.tatar.ru урнаштырырга һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга, җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Аксубай муниципаль районы
Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы А. В. Макаров